КАРАР

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлегенең Сосновка авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**21 ноябрь 2022 ел** **№ 11**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 21 ноябрендә узган: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Елаур авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидтан тыш, 2023 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Сосновка торак пункты чикләрендә авыл эчендәге җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау (юл катламын күтәрү, ташу, таш җәю, транспорт хезмәтләре күрсәтү) мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 36 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 26 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 26 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлегенең Сосновка авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Елаур авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидтан тыш, 2023 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Сосновка торак пункты чикләрендә авыл эчендәге җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау (юл катламын күтәрү, ташу, таш җәю, транспорт хезмәтләре күрсәтү) мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. , Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, бастырып чыгарырга, мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: О.В.Охотникова
Елаур авыл җирлеге башлыгы: О.В.Охотникова